**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость,
423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы,
423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

**№ 148** **31 октябрь 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Шешминка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советының
2013 елның 13 ноябрендәге 73 номерлы
«Җир салымы турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2013 елның 13 ноябрендәге 73 номерлы «Җир салымы турында» карарына (авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 94 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 111/1 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 86 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   1.1. 2 статьяда:

   - 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: « 1) 0,3% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланучы зоналары составында булган һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен кулланыла торган җирләргә карата;

   - 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «2) 0,3% торак фонд һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына кагылмаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

   - 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4) 0,15% шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган

(бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата»;

- 5 пунктны төшереп калдырырга.
- 6 пунктны 5 пункт дип санарга.

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз законлы көченә керә.
3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Шешминка авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе: М.Д.Шәйхетдинов